ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamaduYsh.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

22 ноябрь 2018 ел №15

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге_гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән «19» ноябрь 2018 елдагы № 905 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Катмыш авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесе Габидуллин И.Г.

Татарстан республикасы
Мамадыш муниципаль
районы,Катмыш авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018 елның
22 ноябрендә №15 ле
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,
Катмыш авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Катмыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019 елнын 28 февраленэ вакытка кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш: 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала , аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә яраксыз булу,

б) эш урыныннан командировкада булу,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне бер айга кадәр кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин,

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарынамуниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында,Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгаруһәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыуставында бигеләнгән тәртиптә,шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыруяки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү

(исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл жирлеге
башкарма комитетының 2018
елның 22 нче ноябрендә № 15ле
карарына 2 нче кушымта

Катмыш авыл жирлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________
Нигезләмә
________________________________________________________________
Сезгә __________________ көнгә кадәргә вакыт эчендә
________________________________________ чараны гамәлгә
ашыру буенча 500 сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге
реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК 040205001
Кабул итеп алучы Сч. № 40101810800000010001
ИНН 1626008921
КПП 162601001
КБК 60511714030100000180 ОКТМО 9268421
Түләүнең билгеләнеше
Узара салым
Җитәкче ______________ ________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - - - - -
________________________________________________________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне
______________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________
Кабул ителде «__» ______________ 20__ ел.
________________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм ______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*